МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.03.2024 Казан ш. № 80

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 13 апрелендәге 138 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 13 апрелендәге 138 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 11 августындагы 304 номерлы, 2023 елның 7 мартындагы 50 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) расларга.

2. Үзгәрешләрдә кырык өченче абзацның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары – Социаль-икътисадый мониторинг департаменты җитәкчесе Р.Д.Әмирхановка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
22.03.2024 ел, № 80
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 13 апрелендәге 138 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

Лицензия бирү лицензия бирү турында гариза һәм аңа кушылган документларның тулы күләмендә Бердәм портал ярдәмендә электрон документ формасында кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә башкарыла.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (юридик зат яки шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру адреслары, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төреннән гыйбарәт, башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә кабул ителгән көннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Юридик затны үзгәртеп кору, кушылдыру формасында үзгәртеп корган очракларда (үзгәртеп корылган юридик затларның хокуклы варисы дәүләт теркәвенә алынган датага бер үк төрле лицензиягә ия булу шарты белән), лицензиатны башка юридик затка кушылдыру рәвешендә үзгәрткәндә, лицензиатның исемен, лицензиатның урнашу урынын үзгәрткәндә, шәхси эшкуарның исемен, фамилиясен һәм (булган очракта) атасының исемен, шәхси эшкуарның яшәү урынын үзгәрткәндә, шәхси эшкуарның шәхесен таныклаучы документ реквизитлары үзгәртелгәндә, үзгәртеп кору формасында үзгәртелә торган лицензиатның яки кушылдыру яки лицензиатны бу юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп коруда катанаш торган лицензиатның һәм (яки) аның хокуклы варисының һәм (яки) юридик затның «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законның(алга таба – 99-ФЗ номерлы федераль закон) $20^1$ статьясының 1 өлешендә каралган эшчәнлек төрләренең берсен генә булса да гамәлгә ашыруга лицензиясе булган очрактан тыш, Министрлык лицензияләр реестрына дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүматны, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында Министрлыкка бирелгән мәгълүматтан башка, лицензияләр реестрына үзгәрешләрне автоматик режимда кертү. Лицензияләнә торган эшчәнлек башкару урыннарының аерым адреслары

буенча эшчәнлек туктатылган очракта, лицензияләр реестрына кушылган документларның тулы күләмендә үзгәрешләр кертү турында гариза кабул ителгән көннән алып дүрт эш көне эчендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү гамәлгә ашырыла.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату лицензиатның лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризасы кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турындагы гаризаны кабул иткәннән соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Лицензияләр реестры Министрлыкның рәсми сайтында һәркем файдалана алырлык итеп урнаштырылган.

Гаризаны кабул итү датасы булып мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү турында Бердәм порталдагы шәхси кабинетына электрон хәбәр җибәрү көне санала. Гаризаны кабул иткәндә, гариза бирү көненнән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал аша лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, гаризаны кабул итү датасы турында билге белән исемлек җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны Бердәм порталдагы шәхси кабинетка җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә башкарыла.»;

2.6.2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы түләнгәнлеген раслый торган белешмәләр (2024 елның 1 гыйнварыннан 2029 елның 31 декабренә кадәр бирелгән гаризалар буенча лицензия бирү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында дәүләт пошлиналарын түләү таләп ителми).»;

2.7 пунктның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләмәгәндә (2024 елның 1 гыйнварыннан 2029 елның 31 декабренә кадәр бирелгән гаризалар буенча лицензия бирү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында дәүләт пошлиналарын түләү таләп ителми);»;

2.8 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен, юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда:»;

унынчы абзацны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракта, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту, лицензиянең гамәлдә булуын туктату, лицензияләр реестрыннан мәгълүмат бирү өчен нигезләр юк.»;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

Дәүләт пошлинасы:

лицензия бирү – 7 500 сум;

лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрләре составында башкарыла торган эшләр турында белешмәләргә өстәмәләр кертү белән бәйле лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү – 3 500 сум;

башка очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү – 750 сум.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгән очракта, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза нигезендә дәүләт пошлинасын түләүне таләп итүче бердән артык нигез буенча иң зур дәүләт пошлинасы түләнә.

Дәүләт пошлинасын түләү реквизитлары:

РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТР МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре

БИК 019205400

казначылык счеты номеры 03100643000000011100

исәп счеты 40102810445370000079

алучы:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, шәхси счет: 04112001020)

ИНН 1655141501

КПП 165501001

ОГРН 1071690045129

ОКПО 82318720

ОКВЭД 84.11.21

ОКТМО 92701000

Түләү идентификаторы КБК 70210807082011000110

Түләнгән дәүләт пошлинасы, дәүләт пошлинасын түләгән затларның юридик яктан әһәмиятле гамәл кылудан баш тарткан очракта, әлеге юридик әһәмияткә ия гамәлне кылган (кыла торган) вәкаләтле органга (вазыйфаи затка) мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

2024 елның 1 гыйнварыннан 2029 елның 31 декабренә кадәр бирелгән лицензия бирү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен тапшырылган гаризалар буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында дәүләт пошлиналары түләү таләп ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, Министрлык һәм (яки) вазыйфаи зат гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтү өчен җибәрелгән документка үзгәрешләр керткән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча да;

2) лицензия бирү:

а) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

г) лицензия алырга теләүче затка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү;

3) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда):

а) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

г) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү;

4) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракта):

а) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

в) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү;

5) лицензиянең гамәлдә булуын туктату:

а) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

в) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү;

6) лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү:

а) Бердәм портал аша алынган гариза  ГИС ТОР КНД системасында автомат рәвештә теркәлә;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

в) лицензиатка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү;

7) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча да.

Лицензия алырга теләүче зат, лицензиат телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен Министрлыкның лицензияләү бүлегенә (алга таба – Бүлек) мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча да консультацияләр бирә, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен башка мәсьәләләр буенча да ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензия алырга теләүче зат, лицензиат мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм лицензияләүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

### 3.3. Лицензия бирү

3.3.1. Гариза Министрлыкка бердәм портал аша тапшырыла.

Лицензиягә дәгъва итүче лицензия бирү турында гаризаны һәм аңа кушылган документларны Регламентның 2.6.1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә электрон документлар формасында тапшыра.

Бердәм портал аша электрон формада гариза биргәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда авторизацияләнә;

Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы

белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Бердәм портал аша алынган гариза  ГИС ТОР КНД системасында автомат рәвештә теркәлә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнгән процедуралар: мөрәҗәгать итүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән, теркәлгән гариза.

3.3.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензия бирү турында гаризаны һәм аңа кушылган документларны эшкә кабул итү;

лицензия алучыга лицензияләү органы тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында лицензия бирү турында гаризаны һәм аңа кушылган документларны кабул итү датасы турында билге белән белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензия бирү турында гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар ГИС ТОР КНД кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: эшкә кабул ителгән гариза, лицензия бирү турында гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушылган документларны раслаучы белдерү.

3.3.3. Бүлек белгече:

Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын (булмавын) билгели;

лицензиягә дәгъва итүче турында мәгълүматны Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра.

Регламентның 2.7 пунктының 3, 4, 5 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында шундый белдерүне җибәрә.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензиягә дәгъва кылучыга  ачыкланган бозуларны утыз көн эчендә бетерү һәм (яки) электрон документ формасында булмаган документларны лицензияләү органының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документ формасында тапшыру кирәклеге турында шәхси кабинетка хәбәр җибәрә. Лицензия алырга теләүче зат тарафыннан, белдерү алынган вакыттан башлап, лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза яки аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензия бирү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензия алырга теләүче затка кире кайтарылырга тиеш.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен  Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, Бүлек белгече лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында боерык проектын әзерли.

Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензия таләпләре үтәлешенә күчмә бәя уздыру турында боерык проектын килештерә, ул лицензияләү мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасарына (алга таба – министр урынбасары) җибәрелә.

Министр урынбасары лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында боерыкны имзалый. Бүлек белгече дәгъвачыга күчмә бәя бирү турында аны үткәрә башланганчы өч эш көне алдан теләсә нинди ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ юллау аша да, хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында боерык, лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында белдерү яки ачыкланган бозуларны бетерү һәм (яисә) булмаган документларны тапшыру кирәклеге турында белдерү, лицензия бирү турындагы гаризаны һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны кире кайтару турында белдерү, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, ягъни лицензия бирү яки лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы Министрлык тарафыннан лицензия бирү турында гариза һәм аңа кушылган документлар тулы күләмендә кабул ителгән көннән башлап исәпләнә.

3.3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның 72 статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

3.3.5. Бүлек белгече (белгечләре) лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен гариза бирелгән урында лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирә.

Лицензия таләпләрен үтәүне күчмә бәяләү нәтиҗәләре буенча ике нөсхәдә бәяләү акты рәсмиләштерелә.

Тикшерү актының беренче нөсхәсе бүлектә саклана. Тикшерү актының икенче нөсхәсе лицензия алырга теләүче затка тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар өч эш көне эчендә башкарыла. Процедура Регламентның 3.3.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне узгач гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү акты.

3.3.6. Күчмә бәяләү барышында лицензия бирү өлешендә Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензия бирүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли һәм аны, килештерү өчен, Бүлек җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензия бирүдән баш тарту турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерыкның расланган, министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән проекты.

3.3.7. Министр урынбасары лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту турында имзаланган боерык.

3.3.8. Бүлек белгече лицензиягә Бердәм порталда шәхси кабинетка дәгъва кылучыга лицензия бирүдән баш тарту турында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерык имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында белдерү.

3.3.9. Лицензия алырга теләүче затның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урынында лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлегенең булуы билгеләнгән очракта, ул бәяләү актында чагылдырыла, бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензия бирү турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.5 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән, килештерелгән боерык проекты.

3.3.10. Министр урынбасары лицензия бирү турындагы боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында имзаланган боерык.

3.3.11. Лицензия бирү турында язу, шул исәптән лицензия бирү турында боерык реквизитлары ГИС ТОР КНД системасында лицензия бирү турында боерык имзаланган көнне автомат рәвештә булдырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензия бирү турындагы боерык имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән язу.

3.3.12. Бүлек белгече лицензия алырга теләүче затка Бердәм порталдагы шәхси кабинетка лицензия бирү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган лицензияләр реестрыннан белешмәләргә сылтамасы булган хәбәрне җибәрә.

Лицензия бирү турындагы гаризада лицензия алырга теләүче зат лицензияләр реестрыннан өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, лицензияләүче орган, лицензия бирү турында Бердәм порталдагы шәхси кабинетка белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, лицензияләр реестрыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ формасындагы өземтәне дә лицензия алырга теләүче затка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар лицензия бирү турында боерык имзаланган көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия алырга теләүчегә лицензия бирү турында белдерү, кирәк булган очракта лицензияләр реестрыннан өземтә.

3.4. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда).

3.4.1. Гариза Министрлыкка бердәм портал аша тапшырыла.

Лицензиат лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм аңа кушылган документларны Регламентның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасына ярашлы рәвештә электрон документлар формасында тапшыра.

Бердәм портал аша электрон формада гариза биргәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда авторизацияләнә;

Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Бердәм портал аша алынган гариза ГИС ТОР КНД системасында автомат рәвештә теркәлә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнгән процедуралар: мөрәҗәгать итүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән, теркәлгән гариза.

3.4.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензияләр реестрына һәм аңа кушылган документларга үзгәрешләр кертү турында гаризаны эшкә кабул итү;

лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм аңа кушылган документларны кабул итү датасын раслаучы белдерүне лицензиатка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар ГИС ТОР КНД кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: эшкә кабул ителгән гариза, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушылган документларны раслаучы белдерү.

3.4.3. Бүлек белгече:

Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын (булмавын) билгели;

гариза бирүче турында мәгълүматны Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра.

Регламентның 2.7 пунктының 3, 4, 5 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында шундый белдерүне җибәрә.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензиатка ачыкланган бозуларны утыз көн эчендә бетерү һәм (яки) электрон документ формасында булмаган документларны лицензияләү органының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документ формасында тапшыру кирәклеге турында шәхси кабинетка хәбәр җибәрә. Лицензиат тарафыннан, белдерүне алган вакыттан башлап, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензиатка кире кайтарылырга тиеш.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, Бүлек белгече лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында боерык проектын әзерли.

Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензия таләпләре үтәлешенә күчмә бәя уздыру турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына җибәрелә.

Министр урынбасары лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында боерыкны имзалый. Бүлек белгече лицензиатка күчмә бәя бирү турында аны үткәрә башланганчы өч эш көне алдан теләсә нинди ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ юллау аша да, лицензиатның электрон почта адресы буенча хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында боерык, лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирү турында белдерү яки ачыкланган бозуларны бетерү һәм (яисә) булмаган документларны тапшыру кирәклеге турында белдерү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны кире кайтару турында белдерү, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын, ягъни лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү яки лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү вакыты Министрлык тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм аңа кушылган документлар тулы күләмдә кабул ителгән көннән башлап исәпләнә башлый.

3.4.4. Белешмәләр алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.3.4 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.5. Бүлек белгече (белгечләре) лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен гариза бирелгән урында лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирә.

Лицензия таләпләрен үтәүне күчмә бәяләү нәтиҗәләре буенча ике нөсхәдә бәяләү акты рәсмиләштерелә.

Актның беренче нөсхәсе бүлектә саклана. Тикшерү актының икенче нөсхәсе лицензия алырга теләүче затка тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар өч эш көне эчендә башкарыла. Процедура Регламентның 3.4.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне узгач гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү акты.

3.4.6. Күчмә бәяләү барышында лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өлешендә Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре  ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли һәм аны, килештерү өчен, Бүлек җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: министр урынбасарына имза куярга җибәрелгән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында килештерелгән боерык проекты.

3.4.7. Министр урынбасары лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында имзаланган боерык.

3.4.8. Бүлек белгече лицензиатка Бердәм порталда шәхси кабинетка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдзн баш тарту турында  көчәйтелгән

квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында белдерү.

3.4.9. Лицензиатның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урынында лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлегенең булуы билгеләнгән очракта, ул бәяләү актында чагылдырыла, Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.4.5 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: министр урынбасарына имзага җибәрелгән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында килештерелгән боерык проекты.

3.4.10. Министр урынбасары лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында имзаланган боерык.

3.4.11. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында язу, шул исәптән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык реквизитлары, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык имзаланган көнне автомат рәвештә ГИС ТОР КНД системасында теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән язу.

3.4.12. Бүлек белгече лицензиатка Бердәм порталдагы шәхси кабинетка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган лицензияләр реестрыннан белешмәләргә сылтамасы булган хәбәрне җибәрә.

Лицензия реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гаризада лицензиат электрон документ рәвешендә лицензияләр реестрыннан өземтә алу кирәклеген күрсәткән очракта, лицензияләүче орган лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәр җибәрү белән бер үк вакытта, лицензиатка лицензияләр реестрыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә өземтә дә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык имзаланган көнне башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензия реестрына үзгәрешләр кертү турында лицензиатка хәбәр итү, кирәк булганда лицензияләр реестрыннан өземтә бирү.

3.5. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракта)

3.5.1. Гариза Министрлыкка бердәм портал аша тапшырыла.

Лицензиат лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм аңа кушылган документларны Регламентның 2.6.1 пунктының 3 пунктчасына ярашлы рәвештә электрон документлар формасында тапшыра.

Бердәм портал аша электрон формада гариза биргәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда авторизацияләнә;

Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Бердәм портал аша алынган гариза ГИС ТОР КНД системасында автомат рәвештә теркәлә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнгән процедуралар: мөрәҗәгать итүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән, теркәлгән гариза.

3.5.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензияләр реестрына һәм аңа кушылган документларга үзгәрешләр кертү турында гаризаны эшкә кабул итү;

лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында лицензияләр реестрына үзгәрешләр

кертү турында гаризаны  һәм аңа кушылган документларны кабул итү датасын раслаучы белдерүне лицензиатка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар ГИС ТОР КНД кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: эшкә кабул ителгән гариза, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушылган документларны раслаучы белдерү.

3.5.3. Бүлек белгече Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын (булмавын) билгели.

Регламентның 2.7 пунктының 3, 4, 5 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында шундый белдерүне җибәрә.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензиатка белдерүне алган вакыттан башлап ачыкланган бозуларны утыз көн эчендә бетерү һәм (яки) электрон документ формасында булмаган документларны лицензияләү органының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документ формасында тапшыру кирәклеге турында шәхси кабинетка хәбәр җибәрә. Лицензиат тарафыннан, белдерүне алган вакыттан башлап, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензиатка кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.2 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ачыкланган бозуларны бетерү һәм (яисә) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында белдерү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кире кайтару турында белдерү, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын, ягъни лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү яки лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү вакыты Министрлык тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм аңа кушылган документлар тулы күләмдә кабул ителгән көннән башлап  исәпләнә башлый.

3.5.4. Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаса, бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык проектын килештерәләр, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык проекты.

3.5.5. Белешмәләр алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.3.4 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган документлар исемлеге Регламентның 2.6.2 пунктының «б», «в» пунктчаларында каралган.

3.5.6. Министр урынбасары лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыкны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура регламентның 3.5.4 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында имзаланган боерык.

3.5.7. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында язу, шул исәптән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык реквизитлары, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык имзаланган көнне автомат рәвештә ГИС ТОР КНД системасында теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән язу.

3.5.8. Бүлек белгече лицензиатка Бердәм порталдагы шәхси кабинетка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган лицензияләр реестрыннан белешмәләргә сылтамасы булган хәбәрне җибәрә.

Лицензия реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гаризада лицензиат электрон документ рәвешендә лицензияләр реестрыннан өземтә алу кирәклеген күрсәткән очракта, лицензияләүче орган лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәр җибәрү белән бер үк вакытта, лицензиатка лицензияләр реестрыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә өземтә дә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык имзаланган көнне башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензия реестрына үзгәрешләр кертү турында лицензиатка хәбәр итү, кирәк булганда лицензияләр реестрыннан өземтә бирү.

## 3.6. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату.

3.6.1. Гариза Министрлыкка бердәм портал аша тапшырыла.

Лицензиат электрон документ формасында лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гариза бирә.

Бердәм портал аша электрон формада гариза биргәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда авторизацияләнә;

Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Бердәм портал аша алынган гариза  ГИС ТОР КНД системасында автомат рәвештә теркәлә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнгән процедуралар: мөрәҗәгать итүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән, теркәлгән гариза.

3.6.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны эшкә кабул итү.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КХД ТОР ГИС системасында лицензиянең гамәлдә булмавы турында гаризаны теркәү көнендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында эшкә кабул ителгән гариза.

3.6.3. Бүлек белгече Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булуын (булмавын) билгели.

Регламентның 2.7 пунктының 1, 3, 5 пунктчаларында каралган гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли, лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында шундый белдерүне җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар
Регламентның 3.6.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң киләсе бер эш көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.6.4. Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 3, 5 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр булмаса, Бүлек белгече лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар
3.6.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проекты.

3.6.5. Белешмәләр алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.3.4 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган документлар исемлеге Регламентның 2.6.2 пунктының «б», «в» пунктчаларында каралган.

3.6.6. Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проектын килештерә, ул министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.6.43 пунктында каралган процедураны тәмамлау көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында килештерелгән боерык проекты.

3.6.7. Министр урынбасары лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерыкны имзалый һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаган көннән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында имзаланган боерык.

3.6.8. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында язу, шул исәптән лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык реквизитлары лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык имзаланган көнне автомат рәвештә ГИС ТОР КНД системасында теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы боерык имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән язу.

3.6.9. Бүлек белгече лицензиатка Бердәм порталдагы шәхси кабинетка көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында хәбәр җибәрә.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризада лицензиат лицензияләр реестрыннан өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, лицензияләүче орган, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында Бердәм порталдагы шәхси кабинетка белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, лицензияләр реестрыннан

көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ формасындагы өземтәне дә лицензиатка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы боерык имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү, лицензияләр реестрыннан өземтә (кирәк булган очракта).

### 3.7. Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү.

3.7.1. Гариза Министрлыкка бердәм портал аша тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче лицензияләр реестрыннан мәгълүматны электрон документ рәвешендә бирү турында гариза бирә.

Бердәм портал аша электрон формада гариза биргәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда авторизацияләнә;

Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

электрон гаризаны 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалый;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Бердәм портал аша алынган гариза ГИС ТОР КНД системасында автомат рәвештә теркәлә.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнгән процедуралар: мөрәҗәгать итүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән, теркәлгән гариза.

3.7.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

конкрет лицензия турында мәгълүмат әзерли;

лицензияләр реестрыннан өземтә яки кабул ителгән карар турында Министрлык актының күчермәсен, сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә формалаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны ГИС ТОР КНД теркәгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә, кабул ителгән карар турында Министрлык актының күчермәсе яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

Конкрет лицензия турында мәгълүмат Бүлек белгеченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә, кабул ителгән карар турында лицензияләүче орган актының күчермәсе яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә рәвешендә җибәрелә.

### 3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 5  нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатаның булуын таныклаучы документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры кәгазьдә тапшырыла яки почта аша, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп яисә Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булган очракта) җибәрелә.

3.8.2. Эшчәнлек алып бару бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, мөрәҗәгать итүчегә төзәтелгән документны шәхсән имзалап тапшыра яки мөрәҗәгать итүче адресына почта юлламасы итеп җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында теләсә кайсы мәнфәгатьле заттан гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»

5.1. Лицензиягә дәгъва итүче, лицензиат дәүләт хезмәтләре күрсәтү барышында Министрлык тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм гамәлгә ашырылган гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка кадәр һәм суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

5.2. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү барышында кабул ителгән карарларга һәм гамәлгә ашырылган гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка кадәр шикаять бирү 210-ФЗ номерлы федераль законның $11^4$ статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Шикаять һәм шикаять бирү вакытын торгызу турында гариза зат тарафыннан электрон рәвештә Бердәм портал ярдәмендә бирелә.

Дәүләт яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар һәм документлар булган шикаять Министрлыкка Россия Федерациясенең дәүләт яки закон белән саклана торган башка сер турындагы закон таләпләрен үтәп, Бердәм порталдан файдаланмыйча, кәгазь чыганакта тапшырыла.

Министрлык карары дәүләт яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар һәм документлар булган шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең дәүләт яки закон белән саклана торган сер турындагы закон таләпләрен үтәп, ул кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә кәгазь чыганакта җибәрелә.

5.4. Шикаятьне гариза бирүче үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирә ала.

5.5. Электрон рәвештә шикаять биргәндә ул Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән имзаларның бер төре белән имзаланырга тиеш.

5.6. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карары һәм (яки) гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Министрлыкның исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында мәгълүмат, яисә гариза бирүче оешманың исеме, әлеге оешманың кайда булуы турында мәгълүмат, яисә ышаныч кәгазе буенча шикаять бирүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне караган вакытта үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карар алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән гариза бирүченең хокукларын бозуга китергән яки китерә алган Министрлыкның шикаять ителә торган карары һәм (яки) Министрлыкның вазыйфаи затының гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүче Министрлык карары һәм (яки) вазыйфаи затның гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган нигезләр һәм дәлилләр. Гариза бирүче

тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тәкъдим ителергә мөмкин;

5) шикаять биргән гариза бирүченең таләпләре.

5.7. Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең шикаять предметына кагылышлы позициясе теркәлергә мөмкин.

5.8. Гариза бирүче шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны кире ала ала. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

5.9. Шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларга бәйле булган очраклардан тыш, Министрлык шикаятьне караганда судка кадәр шикаять бирүнең «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законда каралган мәгълүмати системасын (дәүләт мәгълүмат системасының өстәмә системасын) куллана.

Дәүләт яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар һәм документлар белән бәйле шикаятьне карау Министрлык тарафыннан дәүләт һәм закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, судка кадәр шикаять итү ярдәмче системасын кулланмыйча башкарыла.

5.10. Шикаять бирү срогын җитди сәбәпләр аркасында калдырган очракта, гариза бирүченең үтенече буенча бу срок Министрлык тарафыннан кире кайтарылырга мөмкин, әгәр дә шикаять белән бер үк вакытта срокны торгызу турында гариза бирелгән булса һәм шикаятьне караган Министрлыкның вазыйфаи заты срокны үткәрү сәбәбен хөрмәтле дип таныса, ә срокны торгызу турында гариза бирү срогы акыллы дип танылса.

5.11. Шикаять, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кыскарак срок билгеләнмәгән булса, Министрлык тарафыннан теркәлгәннән соң унбиш эш көненнән артмаган вакытта каралырга тиеш.

5.12. Министрлык шикаять биргән гариза бирүчедән шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документларны соратырга хокуклы. Гариза бирүче әлеге мәгълүматлар һәм документлар буенча сорау җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә аларны тапшырырга хокуклы. Шикаятьне карау вакыты, шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турында сорау җибәрелгәннән соң, рөхсәт органы аларны алганчыга кадәр, әмма сорау җибәрелгәннән соң биш эш көненә кадәр туктатыла. Гариза бирүчедән шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар алмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

5.13. Министрлык шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә, әгәр:

1) шикаять шикаять бирү вакыты тәмамланганнан соң бирелгән һәм шикаять бирү вакытын кире кайтару турында гариза бирелмәгән булса;

2) шикаять бирү өчен уздырылган вакытны торгызу турында үтенечне канәгатьләндерүдән баш тартылса;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче үк аны биргән гариза бирүчедән шикаятьне кире алу турында гариза килгән булса;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары булса;

5) элек вәкаләтле органга шикаять биргән гариза бирүче шул ук предмет һәм шул ук нигезләр буенча башка шикаять биргән булса;

6) шикаятьтә әдәпсез яки мыскыллаучы сүзләр, рөхсәт бирүче органның вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса;

7) элек шул ук предмет буенча һәм шул ук нигезләр буенча шикаятьне караудан баш тартылган булса, бу хәл гариза бирүченең шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген кире какса, һәм яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә;

8) шикаять тиешле булмаган вәкаләтле органга тапшырылган булса;

9) шикаятьнең эчтәлеге дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән карарга һәм гамәлгә ашырылган гамәлләргә (гамәл кылмауга) карамаса.

5.14. Шикаятьне караудан баш тарту турында карар Министрлык тарафыннан шикаять алынган көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә, Регламентның 5.13 пунктының 3 пунктчасында каралган нигез буенча баш тарту турында карарны исәпкә алмаганда. Регламентның 5.13 пунктының 3-8 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча шикаятьне караудан баш тарту судка кадәрге шикаять нәтиҗәсе түгел һәм Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд аша шикаять бирүгә нигез булып хезмәт итә алмый.

5.15. Лицензия биргәндә, лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткәндә Министрлык карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд аша шикаять бирү бары тик эшкуарлык эшчәнлеген башкармаган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү очракларыннан, шулай ук башка федераль законнар белән тиешле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять итүнең суд тәртибе генә билгеләнгән очраклардан тыш кына мөмкин.»;

(Белешмәлек) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны күрсәтүне контрольдә тотучы органнар һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 524-91-11 | mert.pr1@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Министр урынбасары | 524-91-02 | Nasibullina.Guzel@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлеге җитәкчесе | 524-91-48 | Nadezhda.Gornovskaya @tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | 524-91-49 | L.Safin@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече | 524-90-22 | Hasanova.Elmira@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты | 524-91-49 | Olga.Bobkova@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 524-91-68 | Ramziya.Zimina@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәнәгать бүлеге җитәкчесе | 264-76-74 | German.Fashiev@tatar.ru». |